**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

---

**БОЕРЫК**

**БОЕРЫК**

06-07-2015 № 09-16-88

Казан ш.

Татарстан Республикасының сатып алулар буенча
Дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең
хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү буенча
һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссиясы
турында Кагыйдәне раслау

Рәсәй Федерациясе Президентының 821 санлы 01.07.2010 тарихлы "Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссияләр турында" Указына һәм Татарстан Республикасының УП-569 санлы 25.08.2010 тарихлы "Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссияләр турында" Указына туры китереп боерам:

1. Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссия турында Кагыйдәне расларга.

2. Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитеты рәисенең 09-16-110 санлы 29.09.2014 тарихлы боерыгын көчсез итеп билгеләргә.

3. Бу боерыкны үтәү контролен үземә билгелим.

Рәис О.А.Редько

Кушымта

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасының
сатып алулар буенча Дәүләт
комитеты
рәисе
«06» 07. 2015 тарихлы
09-16-88 санлы

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАНЛЫК ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ТАЛӘПЛӘРНЕ ҮТӘҮ ҺӘМ ӘҺӘМИЯТЛӘР КОНФЛИКТЫН ХӘЛ ИТҮ БУЕНЧА КОМИССИЯ ТУРЫНДА КАГЫЙДӘЛӘР**

1. Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссия турында Кагыйдә (моннан соң - Кагыйдә) 79-ФЗ санлы 27 июль 2004 тарихлы "Рәсәй Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәт турында" Федераль законга, 273-ФЗ санлы 25 декабрь 2008 тарихлы "Ришвәтчелеккә каршы хәрәкәт турында" Федераль законга, Рәсәй Федерациясе Президентының 821 санлы 01 июль 2010 тарихлы "Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссияләр турында" Указына, 3-ЗРТ санлы 16 гыйнвар 2003 тарихлы "Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында" Татарстан Республикасының Канунына, Татарстан Республикасының УП-569 санлы 25 август 2010 тарихлы "Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссияләр турында" Указына туры китереп камилләштерелгән. Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе буенча таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссиянең (моннан соң - Комиссия) оештырылу һәм эш тәртибе Кагыйдәләр белән билгеләнә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Рәсәй Федерациясенең Конституциясен, федераль кануннарны, Рәсәй Федерациясе Президентының һәм Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте актларын, Татарстан Республикасының Конституциясен, Татарстан Республикасының кануннарын, Татарстан Республикасының Президенты һәм Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты актларын, бу Кагыйдәләрне, шулай ук Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитеты (моннан соң - Дәүләт комитеты) боерыкларын кулланып эшли.

3. Комиссиянең төп максаты булып ярдәм тора:

а) Дәүләт комитетының дәүләт гражданлы хезмәткәрләренең (моннан соң - дәүләт хезмәткәрләре) чикләмәләр һәм тыюлар, әһәмиятләр конфликтын булдырмау яки хәл итү юлында, шулай ук аларның 273-ФЗ санлы 25 декабрь 2008 тарихлы "Ришвәтчелеккә каршы хәрәкәт турында" Федераль закон, башка федераль

законнар белән билгеләнгән вазифаларын үтәү (моннан соң - хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) әһәмиятләр конфликтын хәл итүгә таләпләр);

б) Дәүләт комитетында ришвәтчелеккә каршы чаралар үткәрүдә.

4. Комиссия Дәүләт комитетында (Татарстан Республикасының Президенты һәм Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты билгели һәм азат итә торган дәүләт хезмәтләре вазифалары урынына калган дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) Татарстан Республикасында дәүләт гражданлы хезмәт вазифалары урынына калган дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) әһәмиятләр конфликтын хәл итүгә таләпләрне үтәү (моннан соң - дәүләт хезмәте вазифалары).

5. Дәүләт комитетында Татарстан Республикасының Президенты билгели һәм азат итә торган дәүләт хезмәтләре вазифалары урынына калган дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) әһәмиятләр конфликтын хәл итүгә таләпләрне үтәү Татарстан Республикасының Президенты Аппаратының хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссия тикшерә.

6. Дәүләт комитетында Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты билгели һәм азат итә торган дәүләт хезмәтләре вазифалары урынына калган дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) әһәмиятләр конфликтын хәл итүгә таләпләрне үтәү Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппаратының хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм әһәмиятләр конфликтын хәл итү буенча комиссия тикшерә.

7. Комиссия Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән барлыкка килә. Күрсәтелгән боерык Комиссия составын һәм аның эш тәртибен билгели.

Комиссия составына Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифалары урынына калучы Комиссия әгъзалары саныннан Дәүләт комитеты рәисе билгели торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзалары. Карар алу вакытында Комиссия әгъзаларының хаклары тиң. Комиссия рәисе юклыгында аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары үти.

8. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) Дәүләт комитеты рәисе урынбасары (Комиссия рәисе); Дәүләт комитетының кадрлар буенча эш башкару буенча оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәр - ришвәтчелек һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы зат (Комиссия сәркатибе); Дәүләт комитеты эшчәнлегенең хокукый ярдәм өчен җаваплы хезмәткәр, Дәүләт комитетыт рәисе билгеләгән башка бүлекчәләр дәүләт хезмәткәрләре;

б) ришвәтчелеккә каршы сәясәт сораулары буенча Татарстан Республикасының Президенты Идарәсе вәкиле;

в) фәнни оешмалар һәм эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле урта, югары һәм өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләре вәкиле (вәкилләре).

9. Дәүләт комитеты рәисе комиссия составына түбәндәгеләрне кертү турында карар алырга хаклы:

а) Дәүлләт комитетына карашлы иҗтимагый совет вәкиле.

б) Дәүләт комитетында булдырыла ала торган профсоюз оешмасы һәм ветераннар иҗтимагый оешмасы вәкиле.

10. Бу Кагыйдәнең 8 санлы пунктның "б" һәм "в" кече пунктларында һәм 9 санлы пунктта күрсәтелгән затлар ришвәтчелеккә каршы сәясәт сораулары буенча Татарстан Республикасының Президенты Идарәсе, фәнни оешмалар һәм белем

бирү оешмалары, һәм урта, югары һәм өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләре, Дәүләт комитетына карашлы иҗтимагый совет, Дәүләт комитетында булдырыла ала торган профсоюз оешмасы һәм ветераннар иҗтимагый оешмасы белән килештерүдән соң Дәүләт комитеты рәисе соравы нигезендә Комиссия составына кертелә ала. Килештерү сорау алынганнан соң 10 көн эчендә эшләнә.

11. Дәүләт хезмәте вазифалары урынына калмаучы Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының чирегеннән аз булмаска тиешле.

12. Комиссиянең составы Комиссия алган карарларын тәэсир итүче әһәмият конфликты барлыкка килү мөмкинлеген юк итәрлек итеп төзелә.

13. Комиссия утырышында киңәш хокукы булган затлар:

а) хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәү буенча комиссия тикшерүче дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе билгеләгән тикшеренү алып барыла торган Дәүләт комитетында дәүләт хезмәтенең вазифасы урына калучы дәүләт хезмәткәренә тиңдәш ике дәүләт хезмәткәре;

б) Дәүләт комитетында дәүләт хезмәтенең вазифасы урынына калучы башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте һәм Коммиссия тикшерә торган сораулар буенча аңлатмалар бирә алучы белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазифалы шәхесләре; кызыксынган оешмалар вәкилләре; хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәү буенча Комиссия тикшерү алып барыла торган дәүләт хезмәткәре вәкиле, - тикшерү алып барыла торган дәүләт хезмәткәренең яки комиссиянең башка әгъзасы үтенүе нигезендә Комиссия утырылышыннан иң азы өчен көн алдан һәр аерым хәлдә алына торган Комиссия рәисе карары буенча.

14. Комиссия утырылышында гомуми Комиссия әгъзаларының өчтән икесе булу очрагында, ул хокуклы булып санала. Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифалары урынына калучы Комиссия әгъзаларының гына катнашында утырышны үткәрү тыела.

15. Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән сорауны тикшерү вакытында әһәмиятләр конфликтына китерә ала торган Комиссия әгъзасының туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксыну барлыкка килгән очракта, ул утырыш башланганчы моның турында хәбәр бирергә тиеш. Бу очракта тиешле Комиссия әгъзасы билгеләнгән сорау тикшерүендә катнашмый.

16. Комиссия утырышы өчен нигезләр:

а) Рәсәй Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына туры китереп башкарылган дәүләт хезмәткәре тәкъдим иткән мәгълүматларның дөреслелеге һәм тулылыгы, һәм дәүләт хезмәткәре ягыннан хезмәт тәртибе таләпләрен үтәвен тикшерү, тикшерү материаллары нәтиҗәсендә Дәүләт комитеты рәисе тәкъдим итүе:

дәүләт хезмәткәре ягыннан Татарстан Республикасының дәүләт гражданлы хезмәт вазифалары урынына калуга дәгъваланучы гражданнар ягыннан Кагыйдәдә билгеләнгән табыш, милек һәм милки характерлы бурычлар турында шикле яки тулы булмаган мәгълүматлар тәкъдим итү турында, шулай ук табыш, чыгымнар, милек һәм Татарстан Республикасының Президенты раслаган УП-702 санлы 30 декабрь 2009 тарихлы Указы белән билгеләнгән милки характерлы бурычлар турында әүләт гражданлы хезмәткәрләр ягыннан тәкъдим итү тырнда;

дәүләт хезмәткәре ягыннан хезмәт тәртибенә һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәмәү турында;

б) кадрлар буенча эш башкару буенча оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә - ришвәтчелек һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы затка:

Татарстан Республиксының Дәүләт комитетында дәүләт гражданлы хезмәт вазифалары, алар урынына калган очракта дәүләт гражданлы хезмәткәрләр үзләренең табышлары, чыгымнары, милекләре һәм милки характерлы бурычлар, һәм иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларның табышлары, чыгымнары, милекләре һәм милки характерлы бурычлары турында мәгълүмат бирергә тиешле, Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән расланган сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада вазифа урынына калырга яки гражданлы-хокукый аңлашма шартларына эшләр башкаруга, әгәр бу оешманың аерым дәүләт идарәсе буенча функцияләре аның вазифалы (хезмәт) йөкләмәләренә кергән очракта, дәүләт хезмәтеннән ике елвакыты тәмамланганчы ризалык бирү турындагы исемлегенә кертелгән, Дәүләт комитетында дәүләт гражданлы хезмәт вазифалары урынына калган гражданинның мөрәҗәгате.

дәүләт хезмәткәренең үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларның табышлары, чыгымнары, милекләре һәм милки характерлы бурычлары турында мәгълүмат бирү объектив сәбәпләргә күрә мөмкин булмаганлыгы турында гаризасы;

Дәүләт хезмәткәренең "Билгеле шәхесләргә хисапларга (керемнәргә) ия булу һәм ачу, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне Рәсәй Федерациясенең чигеннән тышта урнашкан чит ил банкларында саклау, чит ил финанс инструментларын куллану тыелу турында" 79-ФЗ санлы 7 мая 2013 тарихлы Федераль законның таләпләрен кулга алу, чит ил канунчылыгына күрә хисаплар (керемнәр) урнаштырылган, акчалар һәм (яки) кыйммәтле әйберләр булган чит илнең тулы хокуклы органнар ягыннан боерырга тыелу сәбәпле, яки аның яки аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның теләгенә бәйле булмага башка сәбәпләргә күрә;

в) дәүләт хезмәткәре белән хезмәт тәртибе һәм (яки) әһәмиятләр конфликтын хәл итү таләпләрен үтәүне тәэмин итү яки Дәүләт комитетында ришвәтчелеккә каршы чаралар үткәрү буенча Дәүләт комитетының рәисе яки һәртөрле Комиссия әгъзасының мөрәҗәгате.

г) Дәүләт комитетының рәисе тәкъдим иткән "Дәүләт вазифалары урынына калучы һәм башка затларның чыгымнарының табышларына туры килүе буенча контроль турында" Федераль законның 3нче маддәсенең 1 өлешендә күздә тотылган дәүләт хезмәткәре ялгыш яки тулы булмаган мәгълүматлар тәкъдим итүен раслаган тикшерү материаллары;

д) 273-ФЗ санлы 25 декабрь 2008 тарихлы "Ришвәтчелеккә каршы хәрәкәт турында" Федераль законының 12 маддәсенең 4нче өлешенә һәм Рәсәй Федерациясенең Хезмәт кодексының 64.1нче маддәсенә күрә Дәүләт комитетына сәүдә яки сәүдә булмаган оешмадан Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калган гражданин белән Дәүләт комитетында вазифа урынына калу вакытында әгәр бу оешма белән билгеле дәүләт идарә итү функцияләре аның вазифалы (хезмәт) йөкләмәренә керсә, эш башкару (хезмәт күрсәтү) буенча хезмәт яки гражданлы-хокукый аңлашма төзү турында, әгәр белдерелгән гражданинга бу оешма белән хезмәт яки гражданлы-хокукый мөнәсәбәтләргә керү комиссия

тарафыннан тыелган икән, яки бу гражданинга сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада вазифа урынына калу яки гражданлы-хокукый аңлашма шартларында сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада эш башкару мәсәләсе куелмаган булса, килгән белдерү кәгазе.

17. Комиссия җинаять һәм административ хокук бозулар, шулай ук аноним мөрәҗәгатләрне тикшерми, хезмәт тәртибен бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

17.1. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктының икенче абзацында билгеләнгән мөрәҗәгать, Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калган гражданин кадрлар буенча эш башкару буенча оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә - ришвәтчелек һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы затка тәкъдим ителә. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туу вакыты, тору урына адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителүгә кадәрге соңгы ике елда тоткан вазифалары, сәүдә һәм сәүдә булмаган оешма исеме, урнашу урыны, аның эшчәнлеге, дәүләт вазифасы урынына калу вакытында гражданин үтәгән вазифалы (хезмәт) йөкләмәләре, дәүләт сәүдә яик сәүдә булмаган оешмага карата идарәсе буенча функцияләре, аңлашманың төре (эш яки гражданлы-хокукый), аның ниятләнгән вакыты, аңлашма буенча башкарылгын эш (хезмәт) учен түләү суммасы. Дәүләт комитетында кадрлар буенча эш башкару буенча оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә - ришвәтчелек һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы зат мөрәҗәгатләрне тикшерә, һәм алар нәтиҗәсендә 273-ФЗ санлы 25 декабрь 2008 тарихлы "Ришвәтчелеккә каршы хәрәкәт турында" Федераль законының12 маддәсенең таләпләрен күздә тотып дәлилле нәтиҗә әзерләнә. Мөрәҗәгатләр, нәтиҗәләр һәм башка материаллар килгәннән ике эш көне эчендә Комиссия рәисенә тәкъдим ителә.

17.2. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктның икенче абзацындабилгеләнгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән эштән азат ителүгә планлаштыра торган дәүләт хезмәткәре ягыннан тәкдим ителә ала, һәм бу Кагыйдәгә туры китереп Комиссия белән тикшерелергә тиеш.

17.3. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "д" кече пунктында билгеләнгәнбелдерү кәгазе кадрлар буенча эш башкару буенча оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә - ришвәтчелек һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы зат тарафыннан тикшерелә, ул Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калган вакытта гражданинның 273-ФЗ санлы 25 декабрь 2008 тарихлы "Ришвәтчелеккә каршы хәрәкәт турында" Федераль законының 12нче маддәсенең таләпләрен үтәү турында нигезле нәтиҗә әзерли. Белдерү кәгазләре, нәтиҗәләр һәм башка материаллар килгәннән ун эш көне эчендә Комиссия рәисенә тәкъдим ителә.

18. Комиссия рәисе аңа утырыш уздыру өчен нигезләр тоткан мәгълүмат аңа килгәндә:

а) 3 көн эчендә Комиссия утырышының көнен билгели. Шулук вакытта Комиссия утырышын көне билгеләнгән мәгълүмат килгәннән соң җиде көннән соң булмаска тиеш, бу Кагыйдәнең 18.1 һәм 18.2 пункталарында билгеләнгән хәлләрдән тыш;

б) дәүләт хезмәткәре белән хезмәт тәртибе һәм (яки) әһәмиятләр конфликтын хәл итү таләпләрен үтәүне тәэмин итү мәсәләсе тикшерелә торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында

катнашучы башка шәхесләрне кадрлар буенча эш башкару буенча оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә - ришвәтчелек һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы затка килгән мәгълүмат, аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыра;

в) бу Кагыйдәнең 13 пунктының "б" кече пунктында күрсәтелгән шәхесләрне Комиссия утырышына чакыру турында мөрәҗәгатне тикшерә, аны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән кире кагу турында) һәм комиссия утырышында өстәмә материалларны тикшерү турында (тикшерүдән кире кагу турында) карар ала.

18.1. Бу Кагыйдәнең 16 пунктының "б" кече пунктының өченче абзацындакүрсәтелгән гаризаны тикшерү буенча Комиссия утырышы гомумән табышлар, милек һәм милки характерлы бурычлар турында мәгълүмат бирү вакыты беткәннән соң бер айдан артык калмыйча уздырыла.

18.2. Бу Кагыйдәнең 16 пунктының "д" кече пунктында күрсәтелгән белдер кәгазе гомумән чиратта торган (планлы) Комиссия утырышында тикшерелә.

19. Комиссия утырылышы хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәү буенча аңа карата тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калучы гражданиның катнашында уздырыла. Дәүләт хезмәткәренең яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калучы гражданиның язма мөрәҗәгәте булу очрагында, билгеләнгән сорау анның юклыгында комиссия утырышында тикшерелә. Дәүләт хезмәткәренең (анның вәкиленең) утырышка килмәве һәм дәүләт хезмәткәренең билгеләнгән сорауны анның юклыгында тикшерү турында язма мөрәҗәгате булмау очрагында, сорау тикшерелүе кичектерелә. Дәүләт хезмәткәренең мөһим сәбәпсез кабат килмәве очрагында, комиссия сорауны дәүләт хезмәткәре юклыгында тикшерү турында карар алырга мөмкин. Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калучы гражданиның (анның вәкиленең) комиссия утырышына килмәве очрагында, билгеләнгән гражданин яшәү урынын үзгәрткән һәм аңа Комиссия утырылышының көне турында хәбәр итү буенча бөтен чаралар башкарылган шарты белән, Комиссия сорауны билгеләнгән гражданин юклыгында тикшерү турында карар алырга мөмкин.

20. Комиссия утырылышында дәүләт хезмәткәренең яки Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калучы гражданиның (аларның ризалыгы белән) һәм башка шәхесләрнең аңлатмалары тыңланыла, бу сорауларны тикшерүгә китерелгән материаллар тикшерелә, шулай ук өстәмә материаллар.

21. Комиссия әгъзаларына һәм анның утырышында катнашкан затларга Комиссия эшчәнлеге вакытында аларга билгеле булган мәгълүматларны фаш итү тыела.

22. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктның икенче абзацында билгеләнгән сорауны тикшерү нәтиҗәсендә комиссия түбәндәгеләрдәге карарларның берсен ала:

а) дәүләт хезмәткәре ягыннан Татарстан Республикасының дәүләт гражданлы хезмәт вазифалары урынына калуга дәгъваланучы гражданнар ягыннан Кагыйдәдә билгеләнгән табыш, милек һәм милки характерлы бурычлар турында дөрес яки тулы мәгълүматлар тәкъдим итүен билгеләргә, шулай ук табыш, чыгымнар, милек һәм Татарстан Республикасының Президенты раслаган УП-702 санлы 30 декабрь 2009 тарихлы Указы белән билгеләнгән милки характерлы бурычлар турында дәүләт гражданлы хезмәткәрләр ягыннан тәкъдим итү тырнда;

б) Бу пунктның "а" кече пунктында исемләнгән Кагыйдәгә туры китереп тәедим ителгән мәгълүматлар шикле һәм (яки) тулы булмаган дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

23. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктның өченче абзацында билгеләнгән сорауны тикшерү нәтиҗәсендә комиссия түбәндәгеләрдәге карарларның берсен ала:

а) дәүләт хезмәткәре ягыннан хезмәт тәртибенә һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәлгәнен билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре ягыннан хезмәт тәртибенә һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәлмәгән дип билгеләргә; Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәмәүнең мөмкин булмаганын белдерергә яки конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

24. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктның икенче абзацында билгеләнгән сорауны тикшерү нәтиҗәсендә комиссия түбәндәгеләрдәге карарларның берсен ала:

а) әгәр гражданинның оешма белән билгеле дәүләт идарә итү функцияләре аның вазифалы (хезмәт) йөкләмәренә керсә, вазифалы (хезмәт) йөкләмәре сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада вазифа урынына калыга яки әүдә яки сәүдә булмаган оешмада гражданлы-хокукый аңлашма нигезендә эш башкаруга рөхсәт бирергә;

б) әгәр гражданинның оешма белән билгеле дәүләт идарә итү функцияләре аның вазифалы (хезмәт) йөкләмәренә керсә, вазифалы (хезмәт) йөкләмәре сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада вазифа урынына калыга яки әүдә яки сәүдә булмаган оешмада гражданлы-хокукый аңлашма нигезендә эш башкаруны кире кагарга һәм кире кагуны дәлилләргә;

25. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктның өченче абзацында билгеләнгән сорауны тикшерү нәтиҗәсендә комиссия түбәндәгеләрдәге карарларның берсен ала:

а) дәүләт хезмәткәренең үзенең, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларның табышлары, милекләре һәм милки характерлы бурычлары турында мәгълүмат тәкъдим итмәү сәбәбен объектив һәм нигезле итеп танырга.

б) дәүләт хезмәткәренең үзенең, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларның табышлары, милекләре һәм милки характерлы бурычлары турында мәгълүмат тәкъдим итмәү сәбәбен нигезсез итеп танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә билгеләнгән мәгълүматны тәкъдим итү буенча чаралар башкарырга тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең үзенең, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларның табышлары, милекләре һәм милки характерлы бурычлары турында мәгълүмат тәкъдим итмәү сәбәбе объектив түгел һәм билгеләнгән мәгълүмат тәкъдим итүдән баш тарту чарасы итеп танырга. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкдим итә.

25.1. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "г" кече пунктында билгеләнгән сорауныткишерү нәтиҗәсендә комиссия түбәндәгеләрдәге карарларның берсен ала:

а) "Дәүләт вазифалары урынына калучы һәм башка затларның чыгымнарының табышларына туры килүе буенча контроль турында" Федераль законның 3нче маддәсенең 1 өлешенә туры китереп дәүләт хезмәткәре ягыннан тәкъдим ителгән

мәгълүматлар дөрес һәм тулы дип танырга;

б) "Дәүләт вазифалары урынына калучы һәм башка затларның чыгымнарының табышларына туры килүе буенча контроль турында" Федераль законның 3нче маддәсенең 1 өлешенә туры китереп дәүләт хезмәткәре ягыннан тәкъдим ителгән мәгълүматлар ялгыш һәм (яки) тулы түгел дип танырга; Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнарны контроль итү нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура һәм (яки) башка компетенциягә күрә дәүләт органнарына юнәлтергә тәкъдим итә.

25.2. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктның дүртенче абзацында билгеләнгән сорауны тикшерү нәтиҗәсендә комиссия түбәндәгеләрдәге карарларның берсен ала:

а) "Билгеле шәхесләргә хисапларга (керемнәргә) ия булу һәм ачу, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне Рәсәй Федерациясенең чигеннән тышта урнашкан чит ил банкларында саклау, чит ил финанс инструментларын куллану тыелу турында" Федераль законның таләпләрен үтәргә комачаулы торган хәлләрне объектив һәм нигезле итеп танырга;

б) "Билгеле шәхесләргә хисапларга (керемнәргә) ия булу һәм ачу, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне Рәсәй Федерациясенең чигеннән тышта урнашкан чит ил банкларында саклау, чит ил финанс инструментларын куллану тыелу турында" Федераль законның таләпләрен үтәргә комачаулы торган хәлләрне объектив түгел һәм нигезсез итеп танырга; Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкдим итә.

26. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "а", "б", "г" һәм "д" кече пунктларында билгеләнгән сорауларны тикшерү нәтиҗәсендә, һәм нигез булган очракта Комиссия бу Кагыйдәнең 22 - 25, 25.1, 25.2 һәм 26.1 пунктларында билгеләнгәннән башка карар алырга мөмкин. Мондый карар алуның нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышының беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.

26.1. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "д" кече пунктында билгеләнгән сораунытикшерү нәтиҗәсендә Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калучы гражданга таба Комиссия түбәндәгеләрдәге карарларның берсен ала:

а) әгәр оешма белән билгеле дәүләт идарә итү функцияләре аның вазифалы (хезмәт) йөкләмәренә керсә, вазифалы (хезмәт) йөкләмәре сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада вазифа урынына калыга яки әүдә яки сәүдә булмаган оешмада гражданлы-хокукый аңлашма нигезендә эш башкаруга рөхсәт бирергә;

б) Сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада хезмәт аңлашмасы шартларында вазифа урынына калу һәм (яки) сәүдә яки сәүдә булмаган оешмада эш башкару (хезмәт күрсәтү) 273-ФЗ санлы 25 декабрь 2008 тарихлы "Ришвәтчелеккә каршы хәрәкәт турында" Федераль законының 12нче маддәсенең таләпләрен бозуын танырга. Бу очракта комиссия Дәүләт комитеты рәисенә күрсәтелгән хәл турында прокуратура һәм хәбәр биргән оешмага белдерү ясарга тәкъдим итә.

27. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "в" кече пунктында билгеләнгән сорауны тикшерү нәтиҗәсендә Комиссия тиешле карар ала.

28. Комиссиянең карарларын башкару өчен Дәүләт комитетының норматив хокукый актлар, тиешле тшртиптә Дәүләт комитеты рәисе тикшеренүенә тәкъдим ителә торган Дәүләт комитеты рәисе карарлары яки йөкләмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин.

29. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктында билгеләнгә сораулар буенча Комиссия карарлары (комиссия башка карар алмаса) утырышында булган Комиссия әгъзаларының күбесе белән яшерен тавыш бирү рәвешендә алына.

30. Комиссия карарлары утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары кул куела торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктының икенче абзацында билгеләнгән сорау буенча карардан тыш, булган Комиссия карарлары Дәүләт комитеты рәисе өчен тәкъдим характерына ия. Бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктының икенче абзацында билгеләнгән сорау буенча карар мәҗбүри характерга ия.

31. Комиссия беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы вакыты, утырышта булган Комиссия әгъзаларының һәм башка шәхесләрнең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында һәр тикшерелгән сорау, хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәү буенча аңа карата тикшерелә торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазифасын күрсәтеп;

в) дәүләт хезмәткәренә карата дәгъвалар, алар нигезләнгән материаллар;

г) дәгъвалар буенча дәүләт хезмәткәренең һәм башка шәхесләрнең аңлатмалары;

д) утырышта чыгыш ясаган шәхесләрнең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм чыгышларының ыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышы өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, дәүләт органына мәгълүмат керү вакыты;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны алу дәлиле.

32. Комиссия карары белән риза булмаган әгъза үз фикерен язма рәвештә тәкъдим итәргә хаклы, бу язма Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлергә һәм дәүләт хезмәткәре аның белән танышырга тиеш.

33. Комиссия утырыш беркетмәсе утырыштан соң 3 көн эчендә Дәүләт комиеты рәисә юнәлтелә, тулысынча яки аннан алынтылар рәвешендә - дәүләт хезмәткәренә, шулай ук комиссия карары буенча - башка кызыксынган шәхесләргә.

34. Дәүләт комитеты рәисе Комиссия утырышы беркетмәсен тикшерергә тиеш һәм компетенциясе чигендә анда булган тәкъдимнәрне Рәсәй Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән дәүләт хезмәткәренә җаваплылык чараларын куллану турында карар алу вакытында, шулай ук ришвәтчелеккә каршы хәрәкәт оештыру сораулары буенча кулланырга мөмкин. Дәүләт комитеты рәисе Комиссиянең тәкъдимнәрен тикшерү һәм алынган карар турында Комиссиягә язма рәвештә аңа утырыш беркетмәсе килгән вакыттан бер ай эчендә хәбәр бирә. Дәүләт комитеты рәисенең карары якындагы Комиссия утырышында игълан ителә һәм фикер алышмыйча кабул ителә.

35. Дәүләт хезмәткәренең хәрәкәтләрендә (хәрәкәтсезлегендә) Комиссия дисциплинар гаеп сыйфатлары билгеләсә, моның турында мәгълүмат Рәсәй Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән дәүләт хезмәткәренә җаваплылык чараларын куллану турында карар алу өчен Дәүләт комитеты рәисенә тәкъдим ителә.

36. Дәүләт хезмәткәренең хәрәкәтләрендә (хәрәкәтсезлегендә) Комиссия административ гаеп сыйфатлары яки җинаять сыйфатлары билгеләсә, Комиссия

рәисе күрсәтелгән хәрәкәт (хәрәкәтсезлек) эшләү турында мәгълүматны һәм моны раслаучы вәсикаларны 3 көн эчендә хак файдалану органнарына, ә кирәкле очракта - тоткарсыз рәвештә тәкъдим итәргә тиеш.

37. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан алынты хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәү буенча аңа карата тикшерелә торган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшендә теркәлә.

37.1. Комиссия сәркатибы кулы һәм Дәүләт комитеты мөһере белән расланган Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасы урынына калган, бу Кагыйдәнең 16нчы пунктының "б" кече пунктының икенче абзацында билгеләнгән сорау буенча хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) әһәмият конфликтын хәл итү таләпләрен үтәү буенча аңа карата тикшерелә торган, гражданинга кул куйдырып бирелә яки мөрәҗәгатендә күрсәткән адреска белдерү кәгазе белән заказной хат белән Комиссия утырышы көненнән соңгы бер эш көненнән калмыйча юнәлтерелә.

38. Комиссиянең эшчәнлеге оештыру-техник һәм документация тәкъдиме, шулай ук Комиссия әгъзаларын көн тәртибенә кертелгән сораулар, утырыш көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, Комиссия әгъзаларын материаллар белән таныштыру адрлар буенча эш башкару буенча оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә - ришвәтчелек һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.